| | |
|---|---|
| МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ |

ПРИКАЗ № 60/о БОЕРЫК

«05» 04 2018

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2016 елның 19 октябрендәге 176/о номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура торак-коммуналь хуҗалык министрлыгында аларны биләү коррупция куркынычларына бәйле булган, аларны биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти холыклы йөкләмәләре турында һәм хатынының (иренең) һәм балигълык яшенә җитмәгән балаларының керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәте һәм мөлкәти холыклы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга бурычлы булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлегенә үзгәреш кертү турында

Б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгында аларны биләү

коррупция куркынычларына бәйле булган, аларны биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти холыклы йөкләмәләре турында һәм хатынының (иренең) һәм балигълык яшенә җитмәгән балаларының керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәте һәм мөлкәти холыклы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга бурычлы булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында» 2016 елның 19 октябрендәге 176/о номерлы боерыгы белән (Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2017 елның 18 декабрендәге 218/о номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгында аларны биләү коррупция куркынычларына бәйле булган, аларны биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти холыклы йөкләмәләре турында һәм хатынының (иренең) һәм балигълык яшенә җитмәгән балаларының керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәте һәм мөлкәти холыклы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга бурычлы булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлегенә (алга таба – Исемлек), аны кушымтада бирелгән яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә.

2. Юридик бүлек башлыгы Э.Ю. Латыйповага дәүләт теркәвенә алу өчен шушы боерыкның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелүен тәэмин итәргә.

3. Дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге башлыгы Т.В. Титовага:

әлеге боерыкны Исемлеккә кертелгән Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүче Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре игътибарына җиткерергә;

Исемлеккә кертелгән вазыйфаларны биләгән Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы федераль законның 12 статьясы күздә тоткан чикләүләр, бурычлар һәм җаваплылык турында аңлатырга;

тәгаенләштерелгән Исемлекне Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаментына һәм Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсенә тапшырырга.

4. Массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек секторы җитәкчесе Г.С. Миңнехановага әлеге боерыкның «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының рәсми сайтында урнаштырылуын тәэмин итәргә.

5. Әлеге Боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Министр ОТДЕЛ ОРГАНИЗАЦИОННО-ПРОТОКОЛЬНОЙ РАБОТЫ, КОНТРОЛЯ И ДЕЛОПРОИЗВОДСТВА И.Ә.Фәйзуллин

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2016 елның 19 октябрендәге 176/о номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2018 елның «___»_____________ ____ номерлы боерыгы редакциясендә) белән расланды

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгында аларны биләү коррупция куркынычларына бәйле булган, аларны биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти холыклы йөкләмәләре турында һәм хатынының (иренең) һәм балигълык яшенә җитмәгән балаларының керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәте һәм мөлкәти холыклы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга бурычлы булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары

ИСЕМЛЕГЕ

1. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең иң югары вазыйфалар төркемендәге «җитәкчеләр» категориясе вазыйфалары:

министрның беренче урынбасары;

министр урынбасары.

2. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең әйдәп баручы вазыйфалар төркемендәге «ярдәмчеләр (киңәшчеләр)» категориясе вазыйфалары:

министр ярдәмчесе.

3. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең төп вазыйфалар төркемендәге «җитәкчеләр» категориясе вазыйфалары:

эшләр белән идарә итүче;

дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге башлыгы;

бюджет үтәлеше, исәпкә алу һәм хисаплылык бүлеге башлыгы;

юридик бүлек башлыгы;

финанс контроле һәм аудит бүлеге башлыгы;

оештыру-беркетмә эше, тикшерүдә тоту һәм эш башкару бүлеге башлыгы;

ТКХ үзгәртеп кору һәм модернизацияләү бүлеге башлыгы;

ТКХда икътисадый анализ һәм фараз бүлеге башлыгы;

ТКХда исәп-хисапларны координацияләү бүлеге башлыгы;

торак сәясәте бүлеге башлыгы;

җыелма-аналитик бүлек башлыгы;

эксплуатацияләү һәм ТКХ программаларын үтәү идарәсе башлыгы;

калдыклар белән эш итү бүлеге башлыгы.

төзелеш комплексын үстерү идарәсе башлыгы;

төзелеш технологияләре бүлеге башлыгы;

нефть химиясе һәм сәнәгать объектлары төзелешендә катнашу бүлеге башлыгы;

архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсе башлыгы;

шәһәр төзелеше эшчәнлеген тикшерүдә тоту бүлеге башлыгы;

икътисадый анализ һәм дәүләт программаларын төзү идарәсе башлыгы.

4. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең әйдәп баручы вазыйфалар төркемендәге «җитәкчеләр» категориясе вазыйфалары:

бюджет үтәлеше, исәпкә алу һәм хисаплылык бүлеге башлыгы урынбасары;

юридик бүлек башлыгы урынбасары;

мобилизацияле әзерлек, гражданлык оборонасы, гадәттән тыш хәлләр һәм серлелек режимы секторы мөдире;

массакүләм мәгълүмат чаралары белән үзара хезмәттәшлек секторы мөдире;

оештыру-беркетмә эше, тикшерүдә тоту һәм эш башкару бүлеге башлыгы урынбасары;

мәгълүматлаштыру секторы мөдире;

дәүләт сатып алулары секторы мөдире;

административ-хуҗалык секторы мөдире;

җыелма-аналитик бүлек башлыгы урынбасары;

нефть химиясе һәм сәнәгать объектлары төзелешендә катнашу бүлеге башлыгы урынбасары.

5. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең әйдәп баручы вазыйфалар төркемендәге «белгечләр» категориясе вазыйфалары:

эксплуатация һәм ТКХ программаларын үтәү идарәсенең капиталь ремонт программаларын үтәү бүлеге башлыгы;

эксплуатация һәм ТКХ программаларын үтәү идарәсенең ТКХда объектлар эксплуатациясен мониторинглау бүлеге башлыгы;

эксплуатация һәм ТКХ программаларын үтәү идарәсенең коммуналь хуҗалыкны үстерү һәм оператив эш бүлеге башлыгы;

торак комплексын үстерү идарәсенең торак төзелешен үстерү бүлеге башлыгы;

торак комплексын үстерү идарәсенең төзелеш комплексында үзара хезмәттәшлек бүлеге башлыгы;

төзелеш комплексын үстерү идарәсенең социаль-мәдәни объектлар төзелеше бүлеге башлыгы;

архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсенең шәһәр төзелеше сәясәте бүлеге башлыгы;

архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсенең территорияләрне

планлаштыру һәм төзеп тутыру бүлеге башлыгы;

архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсенең архитектура һәм проектлау бүлеге башлыгы;

икътисадый анализ һзм дәүләт программалары төзү идарәсенең планлаштыру һәм индикатив идарә итү бүлеге башлыгы;

икътисадый анализ һзм дәүләт программалары төзү идарәсенең максатчан программалар төзү бүлеге башлыгы;

икътисадый анализ һзм дәүләт программалары төзү идарәсенең төзелештә икътисадый анализ һәм бәя кую бүлеге башлыгы;

финанс контроле һәм аудит бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе;

торак комплексын үстерү идарәсенең торак төзелешен үстерү бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе;

архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсенең территорияләрне планлаштыру һәм төзеп тутыру бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе;

шәһәр төзелеше эшчәнлеген тикшерүдә тоту бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе;

финанс контроле һәм аудит бүлегенең әйдәп баручы консультанты;

дәүләт сатып алулары секторының әйдәп баручы консультанты;

төзелеш комплексын үстерү идарәсенең социаль-мәдәни объектлар төзелеше бүлегенең әйдәп баручы консультанты;

нефть химиясе һәм сәнәгать объектлары төзелешендә катнашу бүлегенең әйбәп баручы консультанты;

архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсенең территорияләрне планлаштыру һәм төзеп тутыру бүлегенең әйдәп баручы консультанты;

шәһәр төзелеше эшчәнлеген тикшерүдә тоту бүлегенең әйдәп баручы консультанты.